# Мөстәкыйль сүз төркеме буларак исем

# *Татар теленнән проект*

- ***Төзеделәр:***

Нигаматуллина А.Р.

Галеева Э.Р.

татар теле һәм

әдәбияты укытучылары

121 нче лицей

# *Максат*

- Исем сүз төркеменең морфологик билгеләрен өйрәнү һәм гомумиләштереп кабатлау.
- Укучыларның белем дәрәҗәсен тикшерү.
- Сүз төркеме буларак, исемнең әһәмиятен билгеләү, аны урынлы куллана белергә өйрәтү.

# Әлеге максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

1. Аңлап укырга,сөйләргә,грамоталы язарга һәм дәреслек белән эшләргә өйрәтү;

2. Исемнең грамматик категорияләрен барлау;

3. Туган телне өйрәнүгә, саклауга, үстерүгә теләк тәрбияләү;

# Проектның актуальлеге

**Проектыбызның темасы бүгенге көндә актуаль. Сөйләмдә исем сүз төркеме бик еш кулланыла. Укучыларның исемне грамматик, стилистик яктан дөрес куллану - проектыбызның актуальлеген билгели.**

# *Көтелгән белем нәтиҗәләре (гипотеза)*

- *Исемнәрнең грамматик категорияләрен истә калдыру һәм дөрес кулланылышка кертү, ягъни исемнәрне килеш һәм тартым белән төрләндерү; исемнәргә берлек һәм күплек сан кушымчаларын дөрес ялгау. Бәйләнешле сөйләм төзү күнекмәләре булдыру.*

# Аңлатма язуы




- Татар теленнән проект эше рус мәктәбенең 4 нче сыйныфы өчен төзелде. Атнага 3 сәгать. Барлыгы-10 сәгать.
- Проект өстендә эш укучылар белән әңгәмә үткәрүдән башлана һәм темага кызыксыну уяту максаты белән укытучының презентациясе күрсәтелә. Сыйныф 3 төркемгә бүленә (көчле, уртача һәм йомшак укучылар).
- Укучылар укытучы тәкъдим иткән дидактик материалларны сайлап алалар, кирәкле информация чыганакларын билгелиләр, төркем эчендә эшләрне бүлешәләр. Проект эшенә кадәр укучылар бәяләү нормалары белән танышалар.

- Татар теле һәм әдәбият буенча гомуми белем бирү стандартын исәпкә алып укучыларның эшләренә бәя бирелә.
- Һәр төркем дәрестә үз презентациясен яклый. Укучылар эшкә бәя бирәләр һәм иң яхшы эшне билгелиләр.
- Проект өстендә эшләгәндә укучының мөмкинчелегеннән чыгып эшләр бирелә. Ул шулай ук классташларыннан, укытучыдан ярдәм сорый ала. Үз эшен үзенә уңай формада тәкъдим итү мөмкинчелеге бирелә.

***универсаль уку гамәлләре***

**Регулятив**

**Коммуни ка- тив**

**Танып-белү**

**Шәхескә ка- гылышлы**

**_Регулятив гамәлләр:_**

- ✔ *уку мәсьәләсен кую;*
- ✔ *планлаштыру;*
- ✔ *прогноз кую;*
- ✔ *контроль;*
- ✔ *коррекция;*
- ✔ *бәяләү;*
- ✔ *саморегуляция;*

**_Коммуникатив:_**

*Балаларны тыңлый белү, әңгәмә кору, берәр . мәсьәләне хәл итүдә катнашу; иптәшләреңнең фикеренә уңай йогынты ясау, хезмәттәшлек итү.*

**_Танып-белү:_**

- ✔ *алгоритм (адымлы);*
- ✔ *уку мәсьәләсен кую;*
- ✔ *уку мәсьәләсен чишү;*
- ✔ *модельләштерү;*

**_Шәхескә якын килү:_**

*шәхеснең әхлаки-рухи сый-фатларын камильләштерү; үз фикереңне башкаларга җиткерү өчен тиешле сүз байлыгы булдыру.*

## *Предмет нәтиҗәләре*

- Телнең төп вазифасы турында белү, татар теленең татар халкының милли теле, ТР дәүләт теле икәнен аңлау;
- Татар теленең фәнни нигезләрен үзләштерү, аның берәмлекләре һәм баскычлары арасындагы бәйләнешне аңлау;
- Ана теленең эстетик вазифаларын аңлау, матур әдәбият анализлаганда сөйләмнең эстетик ягын бәяләүгә сәләтлелек.

# *Проектны үткәннән соң укучыны тикшерү үрнәкләре*

***(проблемалы сораулар, тест, иҗади бирем ярдәмендә укучыларның белемнәрен тикшерү)***

# *Бәяләү графигы*

| Проектка кадәрге эш төрләре | Проект өстендә эш, биремнәр үтәү | Проектны үтәп бетергәннән соң эш төрләре |
|---|---|---|
| Укытучының укучылар белән презентациягә кадәр әңгәмә үткәрүе. Укучыларны төркемнәргә бүлү. Укучыларны бәяләү нормалары белән таныштыру. Дидактик материалларны сайлап алу. | Төркемдә эшләрне бүлешү. Эш планын төзү. Интернеттан мәгълүмат эзләү. Төрле чыганак белән эшләү. Презентация ясау. Укытучы консультациясе. | Проектны яклаганчы, эшләгән эшкә бәя бирү. Презентация - чыгыш ясау. Фикер алышу. |

# Бәяләү критерийлары

## Тест


| Бирем | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|---|
| Max балл | 3 | 1 | 2 | 1 | 3 |

## Иҗади бирем

| Бирем | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|---|
| Max балл | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |

| 9-10 балл | “5” |
|---|---|
| 5-8 балл | “4” |
| 3-4 балл | “3” |

# *Проект нәтиҗәләрен диагностикалау*



# Проблемалы сораулар

- *Исем нәрсәне белдерә?*
- *Исем нинди сорауларга җавап бирә?*
- *Исемнең күплек сан кушымчалары нинди?*
- *Исем нәрсәләр белән төрләнә?*
- *Татар телендә ничә килеш бар?*
- *Чыгыш килешенең кушымчалары нинди?*
- *Исем җөмләдә күбесенчә нәрсә булып килә?*

# *“Исем” темасы буенча тест*

1.Исем нәрсәне белдерә?

А) предметның билгесен;  Ә) предметны;

Б) предметның эшен;  В) предметның санын;

2. Исем нинди сорауларга җавап бирә?

А) кем? нәрсә? Ә) нинди? кайсы? Б) нишли? В) нишләде?

3. Күплек сандагы исемне билгелә .

А) такта;  Ә) урманнар;

Б) укучы;  В) елга;

4. Кайсы сүзләр Кем? соравына җавап бирә?

А) кайчы, урам;  Ә) предмет, акбур;

Б) дәреслек, тәрәзә;  В) укытучы, пешекче;

5. Кайсы сүз чыгыш килешендә?

А) урамнан;  Ә) предметның;

Б) дәреслеккә;  В) укытучыда;

# Ижади бирем

## ИСЕМНЕҢ КҮПЛЕК САНЫ
## (МНОЖЕСТВЕННОЕ ЧИСЛО СУЩЕСТВИТЕЛЬНЫХ)

В татарском языке множественное число имен существительных образуется путем присоединения аффиксов:
*-лар /-ләр; -нар /-нәр (м, н, ң).*
Например:
*Кул — куллар (рука —руки). Урам — урамнар (улица — улицы).*

**1. Напишите существительные во множественном числе.**
а) Такта, китап, укучы, кыз, малай, бала.
ә) Урам, урман, үлән, буран, көн, төн, таң.

**2. Образуйте множественное число и запишите в таблицу.**
Укытучы, әни, су, ипи, келәм (ковер), балан (калина), идән (пол), апа, буран (метель).

| -лар: | -ләр: | -нар: | -нәр: |
|---|---|---|---|

**Запомните! В** татарском языке прилагательное никогда не согласуется с существительным, с которым употребляется.
*Яхшы көн — яхшы көннәр (хороший день — хорошие дни).*

**3. Напишите словосочетания во множественном числе.**
Яңа укучы, яхшы дус, чиста дәфтәр, дөрес җавап, пычрак кул, тәмле аш, зур урман, салкын көн.

**4. Переведите. Образуйте множественное число.**
Красивый праздник, новая школа, хороший ответ, чистая рука.
**Запомните!** В татарском языке существительные употребляются с числительными только в единственном числе. Например:
*Китап — китаплар — 2 китап (две книги).*

**5. Переведите.**
Ученик — ученики — 5 учеников. Цветок — цветы — 2 цветка. Слово — слова — 3 слова. Урок — уроки — 4 урока.

# Укытучыга инструкция.

1. *Проект белән танышу;*
2. *Проект белән балаларны таныштыру;*
3. *Әлеге тема буенча балаларга мәгълүмат бирү (7 сәг.);*
4. *Алынган мәгълүматны гомумиләштереп кабатлау (2 сәг.);*
5. *Белемнәрне тикшерү ( тест, иҗади бирем)*
6. *Нәтиҗәләр белән таныштыру.*

# Кулланылган әдәбият исемлеге:


1. *Татар теле: Рус телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 4нче с-фы өчен д-лек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) / Ф.С.Сафиуллина, К.С.Фәтхуллова.– Тулыл.2нче басма. – Казан: Мәгариф, 2010.- 175 б. : рәс. б-н.*
2. *Тесты по татарскому языку: для 4 класса четырехлетней начальной школы (для русскоязычных учащихся) / К.С.Фатхуллова, А.Н.Газизова – Казань: Гыйлем, 2010. – 32 с.*
3. *Хайдарова Р.З., Малафеева Р.Л. Татарский язык в таблицах: Таблицы по татарскому языку для работы с русскоязычными учащимися Наб. Челны, 2005. – 36 стр.*
4. *Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар теле һәм әдәбияты укыту программасы. Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010 Харисов Ф.Ф., Харисова Ч. М., Айдарова С.Х. Татарский язык в иноязычной аудитории: программа и методические рекомендации.- Казань: ТГГПУ, 2007.*

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт